# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья.** «Мәгариф турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1982-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1997 елның 2 июлендәге 1247 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 8-9) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 13 статьяда:

3 пунктта «(республика һәм коммуналь)» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләрен «законнар нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

2. 29 статьяда:

2 пунктның дүртенче абзацында «, мәгариф учреждениеләре турындагы бердәм нигезләмәләрне» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«– укучыларны, тәрбияләнүчеләрне, студентларны, мәгариф учреждениеләренең педагогия хезмәткәрләрен матди тәэмин итүнең нормаларын һәм төрләрен билгеләү, шулай ук законнар нигезендә өстенлекле ташламалар бирү;».

3. 30 статьяның 3 пунктында:

«ж» пунктчасын төшереп калдырырга;

«з» – «п» пунктчаларын тиешенчә «ж» – «о» пунктчалары дип санарга.

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**3 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты
М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
2002 елның 17 гыйнвары
№ I286